**Г.Н.Сафина, Г.Н.Хөснуллина**
*Казанский (Приволжский) федеральный университет,*
*МБОУ “Гимназия №6” г.Казани*

# Русча-ногайча сүзлектә савыт-саба атамаларының бирелеше

*матди мәдәният, савыт-саба атамалары, сүзлек, лингвомәдәният, төрки телләр*

Милләтнең матди һәм рухи мәдәниятенә караган сыйфатлары телнең лексик дәрәҗәсендәге берәмлекләргә туплана. Шунлыктан лексик байлыкны төрле аспектлардан чыгып өйрәнү тел белемендә һәрвакыт актуаль юнәлешләрдән санала. Соңгы вакытта матди һәм рухи мәдәният төшенчәләрен бик еш ишетергә туры килә. Рухи мәдәнияткә театр, музыка, дин һ.б. керсә, матди мәдәнияткә бакчачылык, игенчелек, җитештерүчәнлек һәм башка төр эшчәнлек керә.

Матди мәдәниятне чагылдырган предметлар, нигездә, көндәлек тормыш-көнкүреш өлкәсендә кулланыла. Көнкүреш лексикасы һәм матди мәдәният күренешләре чагылдырган сүзләр күпмедер дәрәҗәдә туры килә. Алар матди мәдәниятнең төп өлешләре буларак карала. Теләсә кайсы телнең сүзлек составында әлеге халыкның тормыш-көнкүрешенә караган лексика шактый зур урын били. Нәкъ менә аларда яшәү өчен иң мөһим предметлар һәм күренешләр ачык чагылыш таба. Көндәлек кирәк-яраклар, ашамлыклар, савыт-саба, кием, торак матди мәдәниятне өйрәнүдә төп чыганак объектларны тәшкил итә [Нурмөхәммәтова 2011: 159].

Төрки телләрнең сүзлек составы бай һәм үзенчәлекле, бигрәк тә күп өлкәләрне үз эченә алган тормыш-көнкүреш лексикасы. Шулар арасында савыт-саба атамалары һәм кухня кирәк-яраклары аерым игътибар үзәгендә тора. Боларга төрле зурлыкта һәм формаларда булган кашыклар, чокыр-чынаяклар, чүмечләр һәм башка савыт-сабалар керә. Элек савыт-сабалар күбрәк агачтан эшләнгән, соңрак фарфор һәм металлдан да әзерләнә башлаган. Һәрбер савыт-сабаның үз атамасы бар, кайчагында шул бер предметның берничә мәгънәсе һәм атамасы да булырга мөмкин. Алга таба шуларның кайберләрен тулырак карап китик. Моның өчен чыганак итеп русча-ногайча сүзлек файдаланылды [Русско-ногайский словарь 1956].

Русча-ногайча сүзлектән тупланган савыт-саба атамалары түбәндәге классификация нигезендә бүленде:

– ризык әзерләү өчен кулланыла торган савыт-саба атамалары: *бадья* – бадья (*агаштан этилген уьйкен шелек*) (РНС 1956, 33), *горшок* – шоьлмек, савыт (РНС 1956, 135), *кастрюля* – кастрюля (*аяк-савыт*) (РНС 1956, 245), *ковш* – шоьмиш (РНС 1956, 252), *корыто* – олык, табак (РНС 1956, 267), *мясорубка* – мясорубка, эт шапалагыш (РНС 1956, 313), *нож* – пышак, макар (РНС 1956, 358), *самовар* – самовар (РНС 1956,

550), *сито* – элек (РНС 1956, 569), *скалка* – оклав (РНС 1956, 570), *сковорода, сковородка* – таба (РНС 1956, 572), *тёрка* – уваткыш (РНС 1956, 617), *треножник* – уьш аяк (РНС 1956, 630), *тяпка* – шапкы (РНС 1956, 639), *чайник* – шайник (РНС 1956, 692), *шумовка* – суьзгиш, шолпы (РНС 1956, 710) һәм башкалар.

– ризыкны саклау өчен кулланыла торган савыт-саба атамалары: *бак* – бак (*сув куйылатаган уьйкен савыт*) (РНС 1956, 33), *банка* – банка, савыт (РНС 1956, 34), *бидон для молока* –суьт куяр уьшин бидон (РНС 1956, 49), *бочка* – бочка, боькше (РНС 1956, 56), *ведро* – шелек (РНС 1956, 68),*кадка* – бочка (РНС 1956, 241), *кувшин* – шоьлмек, кувшин (*тар авызлы шоьлмек*) (РНС 1956, 274), *термос* – термос (*ишиндеги заттынъ йылылыгын бир аьлде саклайтаган савыт*) (РНС 1956, 617), *фляга, фляжка* – фляга, фляжка (*йолга шыкканда сув яде с.б. зат куятаган кишкей савыт*) (РНС 1956, 679) һәм башкалар.

– ризыкны табынга бирү өчен (сервировкалау өчен) кулланыла торган савыт-саба атамалары: *бокал* – бокал (*уьйкен рюмка*) (РНС 1956, 54), *кружка* – кружка (*стаканга усаган саплы савыт*) (РНС 1956, 273), *ложка* – касык (РНС 1956, 287), *чайная ложка* – шай касык (РНС 1956, 287), *столовая ложка* – столовый касык (РНС 1956, 287), *подстаканник* – стакан олтырткыш (*саплы болып, стакан олтыртылатаган бир савыт*) (РНС 1956, 438), *сахарница* – секер салгыш (РНС 1956, 552), *стакан* – стакан (РНС 1956, 594), *тарелка* – тепшек (РНС 1956, 613), *чайница* – шай савыты (РНС 1956, 692), *чарка* – чарка (*ишки ишилетаган кишкей савыт*) (РНС 1956, 692), *чаша* – аяк, тостакай (РНС 1956, 693), *чашка* – чашка, шын аяк (РНС 1956, 693) һәм башкалар.

Әлеге русча-ногайча сүзлектә (1956) 70 ләп савыт-саба атамасы урын алган.

Башка төрки телләрдә кулланылган, җыйма, гомуми мәгънәдә булган *табакъ-сауут, сауут-саба, аякъ-къашыкъ* кебек атамалар, шулай ук ногай телендә дә *савыт-саба* формасында очрыйлар. Ногай телендә *табакъ-аякъ* “чаша” (агачтан, фаянстан (керамикадан) яки металдан) гадәттә ашны яисә башка ризыкны табынга бирү өчен, беренче ризыклар өчен *сорпа аяк* (большая пиала), чәй өчен *шай аяк* кулланылган. Тәлинкә ногай телендә *тепшек, сай тепшек* “сай тәлинкә”, *ялпак тепшек* “тигез тәлинкә” вариантларында очрый. Карачай-балкар телендәге *бал аякъ* атамасы ногай телендә *сербетсув аяк* дип йөртелә. Шулай ук “садакъа аякъ” варианты да бар. Бу ритуаль чынаяк, аңа җиде төрле ризык салалар һәм мәетне ишегалдыннан ачып чыкканчы, башта әлеге савытны алып чыгалар. Аны ризыклары белән бергә ятимнәргә, мохтаҗларга бирәләр. Ногайлар бу йоланы *садака шыгарув* дип атыйлар [Ногайцы 2016: 274-275].

Агачтан эшләнгән вак савыт-сабалар өчен аерым атамалар кулланылган. Мәсәлән, *тузлукъ аякъ* – пиала для соуса, приготовленного из айрана / сметаны, с добавлением соли, различных приправ. Табынга бал бирү өчен *бал аякъ* “мелкая чаша для меда”

файдаланылган, ләкин аны эчә торган балны салу өчен булган *бал аякъ* “чаша с медовым напитком” белән бутарга ярамый. Шулай ук *туз салгыш* “чаша с сахаром”, *секер салгыш* “чаша с солью” атамалары да бар. Агачтан яки металдан ясалган кашык ногай телендә *касык* “ложка”, *шай касык* “чайная ложка”, *темир касык* “столовая ложка” дип бирелә.

Ногай халкы ризыкны *казанда* (котел) әзерләгән. Савыт-сабалар агачтан гына түгел, камыштан да ясалган. *Шолпы, шомака, шоьмиш* – чүмечнең төрләре, агачтан булган; *шорга*, *агаш аяк*, *тостакан* – чокырчынаяклар; *тепсе, табак* – зур тәлинкәләр, кайчак поднос ролен дә үтәгәннәр; *шара* – зур мискин; *оклау* – камыр җәю өчен уклау; *баста-балак* – ботка болгату өчен калак; *авык* – киле. Камыштан чәй һәм сөт сөзү өчен *суьтлик* (сөзгеч) әзерләгәннәр. Балчыктан ясалган чүлмәкләрдә (*шоьлмек*) күбрәк сөт һәм сөт ризыкларын саклаганнар. Күннән тегелгән турсыклар (*саба*, *тулык*, *торсык*, *артпак*) да киң кулланылышта булган. Кайбер сөт ризыкларын киптерелгән кабактан ясалган *кабак-аяк* дигән савыттан ашаганнар. Коедан су алу өчен күн чиләкләрдән (*кавга*, *шелек*) файдаланганнар [Керейтов 2009: 230].

Ногай халкының ризыгы, аны әзерләү ысуллары, ризык һәм савыт-саба атамалары аларның күп милләтләрдә, шул исәптән, төрки булмаган милләтләрдә дә таралган булуын күрсәтә, бу Евразия киңлекләрендә милләтләрнең тыгыз бәйләнештә булуына һәм борынгылык файдасына бер дәлил.

**Әдәбият**


Керейтов Р.Х. Ногайцы. Особенности этнической истории и бытовой культуры / науч. ред. Ю.Ю.Клычников; Карачаево-Черкесский институт гуманитарных исследований. – Ставрополь: Сервисшкола, 2009. – 464 с.

Ногайцы: XXI век. История. Язык. Культура. От истоков – к грядущему. Материалы Второй Международной научно-практической конференции (г. Черкесск, 12–13 октября 2016 г.). – Черкесск, 2016. – 600 с.

Нурмөхәммәтова Р.С. Татар халкының матди мәдәниятен чагылдырган лексик берәмлекләр буларак азык-төлек атамалары / Р.С.Нурмөхәммәтова // Татар лингвокультурологиясе: проблемалар һәм перспективалар: II республикакүләм фәнни-гамәли конференция материаллары. 2 кисәк (Казан, 11 нче февраль, 2011 нче ел). – Казан: ТДГПУ, 2011. – 278 б. – Б. 159–163.

Русско-ногайский словарь. Около 20 000 слов / под ред. Н.А.Баскакова. – М.: Гос. изд-во иностр. и нац. словарей , 1956. – 734 с.